Молотова, Г.М. Современное состояние уйгурской фольклористики Казахстана и СУАР КНР / Г.М. Молотова // Центральная Азия – Китай: состояние и перспективы сотрудничества. – Алматы: Казахстанский институт стратегических исследований при Президенте Республики Казахстан, 2008. – С. 276-287.

Мугтасимова, Г.Р. Татарские народные пословицы, отражающие ежличностные отношения в семье / Г.Р. Мугтасимова // Сопоставительная филология и полилингвизм: Материалы еждународной научной конференции (Казань, 29 сентябрь - 1 октября 2010 года). – Казань, 2010. – С.199-201.

Исәнбәт, Н. Татар халык мәкальләре. 1 том / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.

Исәнбәт, Н. Татар халык мәкальләре. 2 том / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.

Исәнбәт, Н. Татар халык мәкальләре. 4 нче басма / Н. Исәнбәт. – Яр Чаллы: «Идел-йорт», 2003.

Хамраев, М.К. Уйгурские пословицы и поговорки / М.К. Хамраев. – Москва: Главная редакция восточной литературы. – 181 с.

***Мөхәммәтгалиева Зилә Муллахмәтовна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

# МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ ЛӘМБРӘ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНДА БАЛА ТУУ ЙОЛАСЫ ЛЕКСИКАСЫ

*В обществе интерес к татарскому языку становится все больше и больше. В этнографических исследованиях уделялось немало внимания на изучение истории обычаев татарского народа. Она нашла отражение в работах Ф.С. Баязитовой [1993], Д.Б. Рамазановой [2002], Г.Т. Бакиевой [1997]. Задачей настоящей статьи является попытка больше изучить и накопить информацию ритуальной лексики, используемой при рождении ребенка в Лямбирском районе Республики Мордовия.*

**Ключевые слова:** *рождение ребенка, этнолингвистика, обряд, верование, приношение.*

*In the public interest in the Tatar language is becoming more and more. In ethnographic studies much attention was paid to the study of the history of traditions of the Tatar people. . It was reflected in the works of F.S. Bayazitova [1993], D.B. Ramazanova [2002], G.T. Bakieva [1997]. The objective of this article is an attempt to learn and accumulate information about ritual vocabulary, which used in the birth of a child in the Lyambirsky District of the Republic of Mordovia.*

**Key words:** *Childbirth, ethnolinguistics, rite, belief, offering.*

Татар халкында бала туу белән бәйле булган йолалар һәм аларга караган сүзләр артык күп сакланмаган. Шулай да кайбер өлкән кешеләр баланы һәм бала тудырган хатынны «явыз рухлардан» саклау, төрле

ышанулар, ырымнар белән үрелеп бара торган, буыннан-буынга күчеп тапшырылып килгән борынгы йолаларны әле дә хәтерлиләр.

Бала туганчы ук, аның исән-сау килеш тууы, киләчәк язмышы, баланың нинди җенестә булуын белү теләге, булачак ананы гына түгел, аның туганнарын да, якыннарын да борчылырга мәҗбүр итә.

Әни булырга әзерләнгән хатын-кыз, нигездә, көтелгән баланың тынычлыгын һәм бәхетен гарантияләүче йолаларны төгәл итеп үтәргә тырыша.

Бала табарга булыша торган йола һәм башка магик гамәлләр туй барышында ук башлана. Мәсәлән, балалары тусын дигән теләк белән, кияүнең ишегалдына кергәндә, киленнең итәгенә кечкенә бала, нигездә күп балалы гаиләдәге малай, куеп торганнар, кыз аңа әзерләгән бүләген бирә.

Бала көтү белән бәйле күп кенә тыюлар бала табуның җиңел үтүе һәм туачак баланың сәламәт булуы максатыннан эшләнә.

Бала көткәндә кайбер кагыйдәләрне сакламаган очракта бала табу авыр булачак дигән ышанулар таралган. Мәсәлән,

- бала көтүче хатын-кызга таяк аша атлап чыгарга ярамый;

- бала көтүче хатын-кыз аша да кемнеңдер атлап чыгуы тыела – бу очракта бала да аркылы ятарга мөмкин дигән ышану бар;

- шул ук максатлардан чыгып, түбә юу да тыела;

- бала көтүче хатын-кызга мәеткә карарга ярамый. Бу очракта баланың йөзе дә мәетнеке кебек ак төстә булырга мөмкин. Моны, киемгә энә яки булавканың очлы ягы белән идәнгә каратып кадаган очракта булдырмый калып була, диләр [Баязитова, 2003: 150].

Шулай ук *курку*га карата да ышанулар бар, бигрәк тә янгынга карау куркыныч санала. Бу вакытта үзеңнең тәнеңә кагылу, бигрәк тә йөзгә, башка, баланың тәнендә кызыл-кара кан таплары калуга китерергә мөмкин.

Өлкән кешеләр хәтерендә *кендек әби, бала түрәтүче әби* – хатын-кызга дөньяга көтеп алынган бала китерергә ярдәм итүче әби булып саклана. Алар бала табуны җиңеләйтү өчен төрле символик мәгънәгә ия булган гамәлләргә килгәннәр. *Кисү алу* ‘тулгак тоту’ [Рамазанова, 2008: 139]) башлангач, бала тизрәк тусын дип, хатын-кызга бал каптыра торган булганнар. Күп кенә җирләрдә бала тапканда күлмәктәге бауларны, тасмаларны бәйләгәннәр, төймәләрне ычкындырганнар, толымнарны сүткәннәр. *Бала түрәгәннән* ‘тапканнан’ [Баязитова, 2003: 149]) соң бала белән әнисен мунчага алып барып юындыралар, чабалар. Түрәтә торган әби баланың авызына бал тидерә:

*«Ата-ана йоласы,*
*Бәхетле бул, тәүфикле бул»,* - дип *авызландыра.*

Бала урынына – соңгылыкка – аерым игътибар бирелгән: аны билгеле бер җиргә күмгәннәр. Шунда ук баланың берничә көннән төшкән кендеген дә

күмеп куйганнар. Соңгысы тарту көченә ия, диеп билгеләп үтелә. Икенче төрле әйткәндә, «хуҗа»сын ерак җибәрми, һәрчак өенә кайтырга җәлеп итә.
Ләмбрә татарларында да элек хатын-кызлар баланы өйдә таба торган булганнар. Ана баланы тапкач, *соңгылыкны күмгәннәр*: [сынгылыкны күмәләр/ үдә такта астына төшә дә шанда кендек әби үзе үwнең такта астысына казый да күмә// үзенең үwендә//] [Мордовские, 2015: ].

*Бала битлек белән туу* очраклары да булган: [бала битлекмән туса битлеген киптереп сондыкта сакларга кушалар//] . Бу якларда *бала кендеген дә киптереп* саклаганнар. Яңа туган балага явыз көчләр тарафыннан куркыныч яный дип саналган. Баланы җен алмаштырудан саклау өчен, аны өйдә үзен генә калдырмаска тырышалар, кирәк булганда, аның баш очына пычак, кайчы яки дога китаплары кебек предметлар куйганнар.
Балага исем беренче көннәрендә үк кушылырга тиеш. Бала туган гаилә өйгә мулланы чакыра һәм мулла *ат бирә*. Исем кушылмаган очракта, бала авырып китәргә мөмкин. Мулла баланың колагына исемен әйтә, догалар укый, азан кычкыра. бәби туен балага мулла исем кушкач кына ясыйлар: [пирут мулланы йәш'терә / ат куштыра иделәр// аннан соң бәбәй туйы йаси иделәр// кунаклар *тәwәннәр* алып киләләр/ бездә ашлар китермиләр/ бездә падаркалар йасилар/ кем нәрсә мужыт//] [Мордовские, 2015: ]. *Тәwәннәр* – бүләкләр (яулык, материал һ.б.ш. әйберләр).

*Чәч әни* – баланың беренче мәртәбә чәчен алучы хатын-кыз. Бала тугандагы чәче белән торса, елак була, шуңа күрә аны кисәргә кирәк дип санаганнар. Чәч әни баланың әтисенең сеңлесе, яки башка кыз туганы була, аңа соңыннан бүләк бирү каралган.

Баланы әтисе яратсын өчен аны тууга әтисенең күлмәгенә чорнаганнар.

*Төн сәдәкәсе* – бала яхшы йокласын өчен бирелә торган сәдака [Баязитова, 2003: 155]). Бала еласа, йокламаса кичкырын төн сәдакасы кертәләр. Эндәшми-тынмый гына сәдака бирәләр дә чыгып китәләр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, ләмбрә татарларында бала туу белән бәйле йолалар башка төбәкләр белән чагыштырганда бик аерылмый һәм күбесе хәзер дә халыкта онытылмаган.

**Литература**

Бакиева, Г.Т. Обряды и ритуалы, связанные с рождением ребенка у сибирских татар юга Тюменской области / Г.Т. Бакиева Вестник археологии, антропологии и этнографии. – 2015. – № 1 (28). – 123-132 с.

Баязитова, Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. – Саранск, 2003. – 288 б.

Кадирова, Э.Х., Галиуллина, Г.Р., Сайфулина, Ф.С., Юсупова, Ә.Ш. Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. – Казан, 2015. – 313 б.

Рамазанова, Д. Б. Вопросы татарской диалектологии / Д.Б. Рамазанова. – Казань, 2008. – 272 с.